وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

6+

# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

№24 (193). 14 июнь 2013 / 5-шәгъбан-1434

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ

## ФИКЪҺЕ ҺӘМ ФИКЪҺЕ ЫСУЛЫ ФӘННӘРЕ АРАСЫНДАГЫ АЕРМАЛЫКЛАР

**Балигълык (җенси яктан җитлегү) яшенә җиткәннәр тарафыннан үтәлергә тиешле гамәлләр (ягъни аларга шәригать күрсәтмәләренең һәм аның белән бәйле рәвештә кабул ителгән тәртипләрнең мәҗбүри булуы) фикъһе (шәригать хөкемнәре турындагы фән) фәненең өйрәнү предметы булып тора. Сәнәгать ширкәтләренең, сәүдә вәкиллекләренең эшчәнлеге, намаз гыйбадәте, вәкыф милке, караклык, мөлкәтне закладка салу, нәрсәне дә булса арендага бирү, сату-алу кебек мәсьәләләргә карый торган кагыйдәләрнең һәм дәлилләрнең төп нигезен фәнни яктан тикшерү белән фикъһе белгечләре (факиһлар) шөгыльләнә.**



Фикъһе ысулы ул - шәригать тәртипләрен җентекле исбатлаулардан өйрәнеп хөкем (нәтиҗә) чыгару (истинбат) өчен кирәк булган кагыйдәләргә аңлатма бирү белән бәйле фән. Әйтик, гарәп телендә үтәлергә тиешлекне (гарәпчә "вүҗүб" - кирәклек) боерык фигыль ачыклап килә, ә аның кире формасы тыю (гарәпчә "хүрмәт") булуын фикъһе ысулы фәне әйтеп бирә.

Факиһ намаз укуның мәҗбүри яки мәҗбүри булмавы турында нәтиҗә (карар) чыгарганда иң элек Коръәндәге "Намаз укыгыз" дигән аятькә ("Бәкара" сүрәсенең 43 нче аяте) мөрәҗәгать итә.

Зәкят мәсьәләсе дә шул ук тәртип буенча карала. Хаҗ гыйбадәтен ачыклап бирү таләп ителгәндә фикъһе белгече дәлил сыйфатында пәйгамбәребез Мөхәммәд (с. г. в.) хәдисен китерә: "Аллаһ Сезнең өстегезгә хаҗ кылуны йөкләде. Аны үтәгез!" (Нәсаи, Мәнәсик, 1). Исерткеч эчемлекләргә кагылышлы мәсьәләләргә чишелеш табу турында сүз барганда, факиһ Коръәннең түбәндәге аятен искә ала: "Әй, мөселманнар! Исерткеч эчү, азгын уеннар уйнау, табынгыч сыннарга баш ору, ырымланган уклар белән шобага салу шайтан гамәлләредер, шакшылыктыр, мондыйлардан ерак торыгыз: котылырсыз (бәхеткә ирешерсез)" ("Әл-Маидә" сүрәсенең 90 нчы аяте).

Фикъһе ысулын белгечлек итеп алган галим төрле мәсьәләләрне аерым яклап өйрәнү белән шөгыльләнми. Ул бөтенесен үз эченә ала торган нигезгә ия кагыйдәләр эшли. Аның тарафыннан билгеләнгән закончалыклар фикъһе белгеченә хокукка бәйле сораулар буенча нәтиҗә (карар) чыгарырга ярдәм итә. Шуның белән бергә факиһ тулы яки аерым рәвештә һәрбер мәсьәләне өйрәнә, аерым моментларны һәм дәлилләрне карый. Моннан тыш, ул һәрбер проблемага күпьяклап бәя бирә, мәсьәләгә төрлечә якын килү мөмкинлекләрен тәкъдим итә. Дөресрәге, фикъһе ысулы - факиһ кулланырга тиешле дәлил һәм ысулларның (чыганакның әһәмиятенә бәйле рәвештә) башлангыч квалификациясен ясап, аларны куллану тәртибен аңлатучы фән. Иң элек Коръәннән, Сөннәттән, аннан соң кыястан һәм шуннан соң гына Коръән һәм Сөннәттә чагылыш тапмаган дәлилләрне кулланырга була. Фикъһе - бу кагыйдәләргә таянып ясалган дини күрсәтмәләр җыелмасы.

Фикъһе белән фикъһе ысулы бәйләнеше башка фәлсәфи фәннәр арасында мантыйкның (логиканың) тоткан урынына тиң. Гарәп телендә дөрес сөйләү һәм хаталарсыз язу өчен грамматика фәне кирәк булган кебек, фикъһе ысулы факиһны хаталардан саклау өчен кирәк. Фикъһе ысулы төрле сорауларга җавап биргәндә хата җибәрүдән саклый. Бары тик фикъһе ысулы фәненә таянып, факиһ хокук нормаларына кагылышлы сорауларда үзе чыгарган карарның дөреслеген аңлый ала.

***Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН***

## КУКМАРАНЫҢ "ИМАН КИЧӘСЕ"

**Күптән түгел Кукмара мәдәният йортында "Мөселманнар җыены" кысаларында "Иман кичәсе" уздырылды. Аны Кукмара мөхтәсибәте белән Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте оештырган иде.**




Танышларым арасында, биш вакыт намазда булмасалар да, дин юлыннан баруымны хуплаучылар шактый. Шулай да, кайчак алар мөселманнар яшәү рәвешендәге кайбер нәрсәләргә аптырый: әйтик, ничек хәмерсез, җыр-биюләрсез һәм уен-көлкесез күңел ачып була икән ул, диләр... Кукмара бистәсендә узган "Иман кичәсе" аларның әлеге "аңламау"ларына ап-ачык җавап булды. Бу көнне районыбыз мөселманнары рухый мәгънәдә ял итте: рәхәтләнеп күңел дә ачты, гыйлем дә арттырып китте.

"Иман кичәсе"н Кукмара мөхтәсибе Зиннур хәзрәт Сәмигуллин ачып җибәрде. Ул әлеге чараны оештыруда ярдәм күрсәткән районның башкарма комитеты мәдәният идарәсе җитәкчесе Гөлнара Закирҗан кызы Гәрәевага мөхтәсибәт һәм кичәгә килгән күпсанлы тамашачылар исеменнән рәхмәт сүзләре җиткерде. Гөлнара ханым исә әлеге кичәне әзерләүчеләргә мөрәҗәгать итеп: "Дини рухтагы мондый чараны күптән уздырасы килеп йөри идек. Шундый мәгънәле, бай эчтәлекле программа әзерләп килгәнегез өчен зур рәхмәт сезгә. Аллаһ кушса, бүгенге "Иман кичәсе" соңгысы булмас. Сезне кабат көтеп калабыз", – дип әйтте.

Дөрестән дә, Диния нәзарәте вәкилләре искитмәле программа әзерләп килгән иде. Дәгъвәт бүлеге хезмәткәрләре Нияз хәзрәт Сабиров, Руслан хәзрәт Фәрхетдиновларның үтемле вәгазьләре, укыган Коръән аятьләре әле дә колакларда чыңлый, Аллаһның рәхмәте булсын аларга!

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

## ЯҢАЛЫКЛАР

### ЯШЬЛӘР ФЕСТИВАЛЕНДӘ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ ВӘКИЛЛӘРЕ ЧЫГЫШ ЯСЫЙ

**9 июнь көнне Казанда Мөселман яшьләре фестивале башланды. Әлеге чарада Россиянең 20 регионыннан йөздән артык яшь мөселман катнаша.** Фестиваль тантаналы төстә Кол Шәриф мәчетендә ачылды. Анда яшьләрне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе урынбасары Нияз хәзрәт Сабиров мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин исеменнән сәламләде һәм фестивальнең уңышлы үтүен теләде. Чараны нәзарәтнең дәгъвәт бүлеге хезмәткәре Руслан хәзрәт Фәрхетдинов алып барды.

10 июнь көнне Нияз хәзрәт Болгарда - "Регина" кунакханәсендә фестиваль делегатларына татарлар тарихында һәм мәдәниятендә диннең роле турында сөйләде. Кунакханәнең икенче залында дәгъвәт бүлеге хезмәткәре Тимергали хәзрәт Юлдашев "Коръән һәм фән" хакында чыгыш ясады.

Фестиваль яшь мөселманнары берләштерү, алар арасында элемтәләр урнаштыру һәм халкыбызның тарихы, рухый байлыгы белән таныштыру максатыннан оештырыла. Шул уңайдан, аның кысаларында нәзарәт вәкилләре, дин әһелләре, галимнәр белән очрашулар, семинарлар үткәрү каралган. Хәләл туклану, көн саен биш вакыт намаз уку, мөселман кинолары карау һ. б. оештырыла.

Фестиваль Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы, татарларның Милли-мәдәни федераль автономиясе, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте, "Идел" яшьләр үзәге, ТР Президенты Эчке сәяси эшләр буенча департаментының Дини оешмалар белән эшләү идарәсе ярдәмендә үткәрелә.

### МӨФТИ ФИНЛЯНДИЯ ГАЛИМНӘРЕ БЕЛӘН ОЧРАШТЫ

**11 июнь көнне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин мөфтияттә Хельсинки университеты теологларын, Евангелия-лютеран чиркәве вәкилләрен кабул итте.** Шулай ук фин татарлары лидеры Окан Дахер белән очрашты. Камил хәзрәт кунакларга Татарстандагы дин үсеше, нәзарәтнең якын киләчәккә планнары турында сөйләде. Ул республикада егерме ел элек 14 мәчет булуын, бүген исә аларның саны мең биш йөзгә якынлашуын әйтте. Моннан тыш, республикада 10 мәдрәсә һәм Россия ислам институты эшләве хакында сөйләде. Нәзарәтнең татар халкы дин галимнәре мирасын торгызу, яңарту максатыннан "Хозур" нәшрияты оештырылуына тукталды.

Төрле диннәрне өйрәнүче сигез теолог Камил хәзрәткә үзләрен кызыксындырган сорауларны бирде. Аларны ислам тәгълиматы белән бәйле теология мәсьәләләре дә кызыксындыра икән. Кунаклар Камил хәзрәтне игътибар белән тыңлады һәм нәзарәттә узган җылы очрашу өчен рәхмәтләрен җиткерде.

### ИГЪЛАН

**30 июнь көнне Балтач районы Бөрбаш авылында VI Республикакүләм мөселман балалар Сабан туе узачак. Башлана: иртәнге сәгать унда (10.00). Барыгызны да көтеп калабыз! Элемтә өчен телефоннар: +7 (84368) 3-39-20, +7 (84368) 3-37-16.**

***Мәгълүматлар Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан алынды***



# ДИНЕБЕЗДӘ ИСЕМНӘРНЕҢ ӘҺӘМИЯТЕ

**Әлхәмду лилләһи раббил галәмин. Вәссаләтү вәссәләмү галә расүлинә Мүхәммәдин вә галә әлиһи вә асхәбиһи әҗмәгыйнь.**

Барча мактаулар Аллаһка гына. Аллаһның хак илчесе Мөхәммәд пәйгамбәргә Аллаһның салават һәм сәламнәре булса иде.

Аллаһы Тәгалә әйтте: "Олуглык һәм хөрмәт иясе булган Раббыңның исеме бәрәкәтле булды" ("Рахмән" сүрәсенең 78 нче аяте).

Раббыбыз Аллаһның исеме генә дә бөек, бәрәкәтле, изгелек китерә. Мөшрикләрнең (ислам динендә булмаучыларның) гыйбадәт кылына торган потлары һәм сыннарының исемнәре, киресенчә, ким-хур итә, кайгы, бәла һәм бәрәкәтсезлек китерә.

Аллаһы Тәгалә әйтте: "Һәм Аллаһның күркәм исемнәре бар, Аңа шулар белән эндәшегез, дога кылыгыз, ялварыгыз" ("Әгъраф" сүрәсенең 180 нче аяте). Аллаһы Тәгаләнең барча исемнәре дә күркәм һәм Ул шул исемнәр белән эндәшкәнне ярата, һәм безне шуңа өнди. Безнең Аңа күркәм исемнәрен әйтеп дога кылуыбыз, догаларыбызның кабул булуына һәм Аллаһның ризалыгына ирешүебезгә сәбәп була.

Пәйгамбәребез (с. г. в.) әйткән: "Аллаһның туксан тугыз исеме бар, бердән башка йөз, кем шуларны санаса, җәннәткә керер". Ягъни, Аллаһы Тәгаләнең исемнәрен санау гына да җәннәткә керергә сәбәп булырга мөмкин.

Бу аятьләрдән һәм хәдисләрдән күренгәнчә, Аллаһы Тәгалә Үзе исемнәргә әһәмият биргән, бу турыда Коръәни-Кәримдә әйткән, шуңа күрә мөселманнар исемнәрнең мөһим икәнлеген, аларның хикмәтле булуын аңларга тиеш.

Аллаһы Тәгалә: "Фәрештәләргә җир йөзендә хәлифә кылачакмын", - дигән. Фәрештәләр: "Анда бозыклык кылучы һәм кан коючыны хәлифә итеп куясыңмыни?" - дигәннәр. Аллаһы Тәгалә аларга Адәм галәйһиссәламнең бөтен исемнәрне дә белүен, ә фәрештәләрнең белмәвен һәм шул сәбәпле Адәмнең (г-м) хөрмәтле зат булуын белгертте һәм аңа сәҗдә кылырга боерды: "Аллаһ Адәмгә исемнәрнең барчасын өйрәтте дә, фәрештәләргә әйтте: "Әгәр дөрес сөйләүчеләрдән булсагыз, Адәм белгән исемнәрнең барчасын да әйтеп бирегез". Фәрештәләр әйтте: "Ий һәр кимчелектән пакь булучы Раббыбыз! Бездә һич белем юк, мәгәр Син белдергәнне генә беләбез, Син, әлбәттә, һәрнәсәне белүче, хикмәт белән эш кылучысың". Аллаһ Адәмгә әйтте: "Фәрештәләрнең барчасын әйтеп бир". Адәм исемнәрнең барчасын әйтеп биргәч, Аллаһ фәрештәләргә әйтте: "Мин сезгә әйтмәдеммени җирдәге вә күкләрдәге яшерен нәрсәләрне беләмен һәм сезнең ачык эшләгән вә яшерен эшләгән эшләрегезне дә беләмен дип?" Хөрмәт йөзеннән Адәмгә сәҗдә кылыгыз", - дип фәрештәләргә әйткән вакытыбызда алар сәҗдә кылды, мәгәр Иблис сәҗдә кылмады, тәкәбберләнде һәм кяферләрдән булды" ("Бәкара" сүрәсенең 31-34 нче аятьләре).

Исемнәрне белү, аларның мәгънәләренә төшенү, һәр әйбергә яки кешегә лаек исемнәр кушу адәм баласының башка мәхлуклардан (җан ияләреннән) өстенлеген, дәрәҗәсен күрсәтә.

Кешеләр үз исемнәренә игътибарлы булырга тиеш, чөнки Аллаһы Тәгалә Үзе кайбер исемнәрне искә алды, хәтта кайбер пәйгамбәрләргә Үзе исем бирде.

"Мәрьям" сүрәсенең 7 нче аятендә: "Әй Зәкәрия, Без сине бер ул (малай) белән шатландырабыз, исеме аның Яхъя, моңа кадәр Без беркемгә дә андый исем кылмадык", - диелә.

"Ул михрабта (гыйбадәт бүлмәсендә) намаз укыганда аңа фәрештәләр эндәште: Аллаһ сине Яхъя белән шатландыра…" ("Әл-Гыймран" сүрәсенең 39 нчы аяте).

"Аллаһ сине Үзенең сүзе белән (ягъни "Бул" дигән сүзе белән барлыкка китерү) шатландыра, исеме аның Мәсих, Мәрьям улы Гыйсә" ("Әл-Гыймран" сүрәсенең 45 нче аяте).

"Һәм минем артымнан килүче илче, рәсүл белән шатландырып, исеме аның Әхмәд (ягъни пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәссәлам)" ("Саф" сүрәсенең 6 нчы аяте).

Мәрьям анабызның да исемен Коръәндә Аллаһы Тәгалә искә ала: "Мин аны Мәрьям дип атадым, һәм мин аны, һәм аның нәселен ләгънәт кылынган шайтаннан Сиңа сыендырам" ("Әл-Гыймран" сүрәсенең 36 нчы аяте).

Аллаһы Тәгалә начар исемнәр куюдан, кушаматлардан тыйды һәм кисәтте: "Начар исемнәр, кушаматлар белән эндәшмәгез, иман китергәннән соң нинди яман эштер алай эшләү, ә кемнәр начар исемнәр, кушаматлар тагудан тәүбә кылмасалар, шулар инде ул залимнәр" ("Хөҗүрәт" сүрәсенең 11 нче аяте).

Ә залимнәр турында Аллаһы Тәгалә әйтә: "Ул көндә, ягъни Кыямәт көнендә аларга гозерләре, сылтаулары файда бирмәс…" ("Рум" сүрәсенең 57 нче аяте).

Пәйгамбәребез (с. г. в.) дә балаларга яхшы исемнәр кушуны боерды. Хәдистә әйтелгәнчә, балага яхшы исем кушу - баланың атасы өстендәге хакы.

Шулай ук Аллаһ илчесе әйтте: "Сезне Кыямәт көнендә исемнәрегез һәм атагызның исемнәре белән чакырырлар, исемнәрегезне яхшы кылыгыз!" (Әбу Дауд); "Аллаһ Тәгаләгә иң сөекле исемнәрегез Габдулла һәм Габдерахман (Мөслим).

Бу исемнәрнең мәгънәләре күркәм: Аллаһның колы һәм Әр-Рахмәннең колы, бу исемнәр кешенең Аллаһны тануын, Аңа буйсынуын, Аңа гына гыйбадәт кылуын белгертеп тора. Шуңа күрә дә Аллаһ мондый исемнәрне ярата. Ә инде ул исемне яраткач, әлбәттә, ул исемне йөртүчене дә Аллаһы Тәгалә ярата, андый исемнәр йөртү Аллаһның ризалыгына ирешүгә сәбәп була. Габд (кол) һәм Аллаһның туксан тугыз исеменең берсе кушылган исемнәр дә шундый ук хөкемдә, мәсәлән: Габдерәхим, Габделәхәт, Габделхаликъ һ. б.

Пәйгамбәребез (с. г. в.) әйткән: "Пәйгамбәр исемнәрен кушыгыз, ә Аллаһка иң сөекле исемнәр: Габдулла һәм Габдерахман, ә иң тугры исемнәр (ягъни хуҗасына туры килә торган): Харис (кәсеп итүче) һәм Һәммәм (тынгысыз, борчылучы); ә иң ямьсез исемнәр: Хәрб (сугыш) һәм Мурра (катылык)".

Мөселман кешесе начар исемнәрдән сакланырга тиеш, чөнки андый исемнәрне, һәм ул начар исем йөртүчене Аллаһ сөйми, шул исеме аңа Аллаһның ачуы һәм газабы килүгә сәбәп була.

Пәйгамбәребез (с. г. в.) әйткән: "Кыямәт көнендә Аллаһның каты ачуына лаек һәм иң әшәкә кеше - үзен Мәликуль-әмләк, яки шаһиншаһ (патшаларның патшасы) дип атаучы. Аллаһтан башка патша юк!"

Аллаһка гына лаек исемнәрдән саклану тиешле. Шундый исемнәрдән: Рахмән (барча мәхлукларга рәхимле булучы), Котдус (мөкатдәс, изге), Халикъ (барча дөньяларны барлыкка китерүче), Әхәд (бердәнбер булучы) һ. б. Кешеләргә бу исемнәр кушыла алмый, чөнки андый сыйфатлар, исемнәр Раббыбыз Аллаһка гына хас, Ул гына андый исемнәргә лаек.

Гайшә (р. г.) әйткән: "Аллаһ илчесе салләллаһу галәйһи вәссәлам начар исемнәрне алыштыра иде" (Тирмизи).

Начар исем кушмау гына түгел, кушылган очракта да аны алыштыру тиеш.

Сәгыйд ибне Әл-Мүсәййиб бабасыннан риваять кыла. "Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вәссәламгә килдем", - ди. Ул әйтте: "Исемең ничек?" Әйттем: "Хәзн (Каты)". Ул әйтте: "Син - Сәһл (җиңел)". Әйттем: "Атам кушкан исемне үзгәртмим". Ибне Әл-Мүсәййиб әйтте: "Шуннан бирле безнең нәселдә катылык һаман бар".

Бу хәдистән аңлашыла: исем кешенең тормышына, холкы-табигатенә дә йогынты ясый, шуңа күрә Аллаһы Тәгалә сөйгән, Пәйгамбәребез (с. г. в.) кушкан исемнәрне кушу кирәк.

Мәгънәләре яхшы булса да, мөселманнар башка өммәтләр йөртә торган исемнәрдән сакланырга тиеш. Чөнки Пәйгамбәребез (с. г. в.) әйткән: "Кем берәр кавемгә охшарга тырышса, шулардан булыр", икенче бер риваятьтә: "Шулар белән кубарылыр", - диелә.

Шуңа күрә динсезләр, христианнар, яһүдиләр, мәҗүсиләр исемнәреннән сакланырга кирәк. Ул исемнәр аны йөртүченең кяфер өммәтләре кешесе икәнлегенең билгесе булып тора.

Аллаһы Тәгалә мөселман өммәтен кешелек өчен җибәрелгән иң хәерле өммәт дип атады. Мөселманнар кешеләргә туры юлны күрсәтүче, изгелекләргә өндәүче, явызлыклардан тыючы, үзләренең бер Аллаһка гына гыйбадәт кылулары белән дә, үз-үзләрен тотышы, холыклары белән дә, тышкы кыяфәтләре һәм чисталыклары белән дә, һәм шулай ук исемнәре белән дә башкаларга үрнәк булырга тиеш. Ул исем аны йөртүче хуҗасының мөселман икәнлеген, бөтен дөньяларның Раббысы булган Аллаһның гына колы икәнлеген күрсәтергә тиеш.

Яхшы исем балага да уңай тәэсир итә. Роберт дип кушсаң, ул Робертка охшарга тырыша, Мөхәммәд дип кушсаң, ул пәйгамбәребез Мөхәммәдкә (с. г. в.) охшарга тырыша. Аллаһ колы Габдулла дип кушсаң, ул Аллаһ колы булырга тырыша. Ә инде кемгә Эт дип исем кушсаң, ул бала, әлбәттә, үзе белән эт арасында охшашлыклар эзләячәк, һәм аңа охшарга тырышачак.

Без, мөселманнар, балаларыбызга күркәм исемнәр, олы максатларга өнди торган, җир йөзендә Аллаһның хәлифәсе булу дәрәҗәсенә лаек исемнәр кушарга тиешбез; кимсетә, хурландыра, кяферләргә охшата торган исемнәрдән саклану лазем.

Балага исем кушу, иң беренче - атаның хакы, анасы яки әбибабасының хакы түгел. Аллаһы Тәгалә болай ди: "Аларны аталарының исемнәре белән йөртегез, бу Аллаһ хозурында гаделрәк, ягъни фәлән улы фәлән, фәлән кызы фәләнә дип" ("Әхзаб" сүрәсенең 5 нче аяте).

Пәйгамбәребез (с. г. в.) дә, сәхабәләр дә балаларына үзләре исем кушканнар. Пәйгамбәребез (с. г. в.): "Бу төндә минем улым туды һәм мин аны атам Ибраһим (ягъни Ибраһим пәйгамбәр) исеме белән атадым", - дигән.

Сәхабәләр шулай ук Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәссәламнән дә балаларына исем куштыра торган булганнар:

"Бер кеше әйтте:

- Я Аллаһның илчесе (с. г. в.), бүген төнлә минем балам туды, аңа нинди исем кушыйм?

Ул әйтте:

- Улыңа Габдерахман дип исем куш".

Яңа туган балага туу белән исем бирсәң дә, җиденче көнендә кушсаң да ярый.

Аллаһның илчесе (с. г. в.) әйткән: "Һәр баланың җенесенә карап, корбан (ягъни бәби туе үткәрү өчен чалына торган малга бәйле (малай булса - ике сарык, кыз булса - бер сарык чалу мөстәхәб, яхшы. - Авт.)) - җиденче көнендә сарык чалына, исем кушыла һәм чәче алына".

Ләкин җиденче көненнән соң да исем кушу ярый, бу турыда да Пәйгамбәребезнең (с. г. в.) хәдисләре бар.

Бер кешенең берничә исеме дә булырга мөмкин, һәм бу шәригатебез буенча тыелмый (әгәр дә ул исемнәр шәригатькә каршы килмәсә).

Мисал өчен, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәссәламнең берничә исеме булган. Ул бу турыда болай дигән: "Минем исемнәрем бәрәү генә түгел: мин - Мөхәммәд, мин - Әхмәд, мин - Мәхий, мин - Хәшир, мин - Гакыйб".



*Рафикъ хәзрәт МИНӘХМӘТОВ, Татарстанның Көнчыгыш регионы казые, Әлмәт районы һәм Әлмәт шәһәре имам-мөхтәсибе, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы әгъзасы*

# САТЫШ МӘДРӘСӘСЕ ЯҢАРТЫЛА

*Үз дене бар аның, үз сүзе,*
*Кол Галиләр белән калыккан,*
*Татар мәктәбенең нигезе*
*Гасырлардан килә...*
*Халыктан.*

**Мөдәррис ӘГЪЛӘМОВ**

**БЕЗ**, сабалылар, 2013-2016 нчы елларга исәпләнгән "Мирас - Наследие" республика максатчан программасы нигезендә Сатыш авылындагы элекке мәдрәсә бинасының яңартылачагын белеп, бик тә куандык.

Әйе, Сатыш мәдрәсәсе заманында төбәгебездәге иң эре уку йортларының берсе булган. XX гасыр башында биредә өч йөзләп шәкерт сабак алган. Әлеге белем һәм тәрбия йорты белән мәхәллә имамнары җитәкчелек иткән. 1996 елда дөнья күргән "Татар халкының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре" дип аталган китапта (авторлары - Р.Салихов, Р.Хәйретдинов) мәдрәсәдә имамлык иткән руханыйлар Мөбарәкша Яруллин (1894 елның сентябреннән имам), Мөхәммәт Мөхәммәтвәлиев (икенче мулла, указы 1872 елның 12 мартыннан) һәм аның улы Габдерахман Мөхәммәтов (1903 елның 26 августыннан имам-хатыйб) исемнәре атала.

Заманында язучы Мәгъсум ага Хуҗин белән "Яшә, Саба-Йорт!" дип аталган китапны (Яшә, Саба-Йорт!: тарихи-публицистик очерк / соавт. М. Хуҗин. - Казан: Матбугат йорты, 1999. - 247 б.) эшләгәндә бу юлларның авторына Байлар Сабасының зыялы, музыкаль нәселеннән булган мөгаллимә, күренекле композиторлар Аллаһияр һәм Хөснулла Вәлиуллиннарның сеңлесе Гөлзар ханым Галиева калын гына бер белешмә-китап биргән иде. Анда Казан губернасы буенча барча төр мәгълүматлар урнаштырылган. Китапның баштагы һәм соңгы битләре булмау сәбәпле, кайчан чыкканы төгәл билгеле түгел. Статистика мәгълүматлары 1914 елныкы, чөнки анда "Прошлого 1914 года" дип башланып киткән җөмләләр байтак. Димәк, белешмә 1915 елда чыгарылган була. Андагы "Мечети и магометанское духовенство Казанской губернии" дигән бүлектә мәчетләр һәм дин эшлеклеләре турында исемлек бирелеп, ул вакытта волость үзәге саналган Сатышның беренче мәхәлләсендә мәдрәсә булуы, Габдерахман Мөхәммәтовның - хатыйб, Габдулла Яруллинның имам булуы күрсәтелгән. Ә инде икенче мәхәлләдә Фәезхан Мөхәммәтовның хатыйб икәнлеге теркәлгән. Шулай итеп, ике китаптагы мәгълүматлар тәңгәл килә.

Икенче бер чыганакта мондый юллар бар: "Совет авылы ике мәхәлләгә бүленгән була. Аның берсендә Габдерахман мулла мәдрәсәдә төшкә чаклы малайларны укыткан, аннан соң Камәрия абыстай кызларга сабак биргән. Икенче мәхәллә балаларына мәдрәсәдә урын булмаганлыктан, Фәезхан мулланың такта белән урталай бүленгән өенең бер ягында малайлар, икенче өлешендә кызлар дин сабагы алган..."

1991 елда Татарстанның халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиев "Без кемнәр?" дигән язма җибәргән иде. Андагы: "Саба районында Сатыш мәдрәсәсе булган. Бу мәдрәсә заманында Арча, Тәкәнеш, Кукмара, Мамадыш, Балык бистәсе яклары өчен шәм-лампа ролен үтәгән. Монда шагыйрь Миргазиз Укмаси (1884-1946), язучы һәм әдәбият белгече Мөхәммәт Гали (1893-1952), шулай ук минем газиз әтием - булачак имам-хатыйб Сөнгатулла укыган. Болар әле мин белгәннәре генә. Бу мәдрәсәдә белем алган шәкертләр камил рәвештә гарәп телен белеп чыккан", - дигән юллар хәтердә уелып калган.

Әмма заманында биредә укыган олы бер шәхескә - дәүләт эшлеклесенә аерым тукталмыйча ярамас. Татарстан Дәүләт Советының хәзерге бинасына кергән кешеләр аның диварына урнаштырылган портретларга игътибар итмичә калмыйдыр: ТАССР Үзәк Башкарма комитеты, Югары Совет һәм Татарстан Дәүләт Советы рәисләре рәсемнәре алар. Шунда сулдан икенче итеп эленгән портрет Сатыш мәдрәсәсенең элекке шәкерте, районыбызның Айдар авылы (хәзер Теләчегә керә) тумасы Рәүф Сабировныкы.

Ә Рәүф Әхмәтсабир улының гомере аянычлы тәмамланганын күпләр беләдер. Азанчы (мәчеттә азан әйтүче) гаиләсендә туган малай белемен күтәрә-күтәрә, җәмәгать эшләрендә катнашып абруй казана. Беренче Бөтендөнья сугышы ветераны ул. Ә инде, алда әйтелгәнчә, 1921-1924 нче елларда ТАССР ҮБК Президиумы рәисе була. 1921 елгы ачлык вакытында Мәскәүгә (Ленин һәм Сталин янына) барып, республикага ашлык кайтарта...

Гомумән, Сатыш мәдрәсәсен тәмамлаган зыялы шәхесләрнең байтагы юкка чыгарыла, сөргенгә җибәрелә, репрессия корбаны була. Шул ук Мөхәммәт Мәһдиевнең әтисе Сөнгатулла хәзрәт тә фәкать мулла булганы өчен кулга алынып, атарга хөкем ителә.

...Миңа моннан бер-ике ел элек Сатыш мәдрәсәсенең имам-хатыйбы, мөдәррисе булып торган Габдерахман хәзрәт Мөхәммәтовның кызы, бөтен гомерен балаларга белем бирүгә багышлаган Суфия апа белән Лесхоз бистәсендә әңгәмә корырга туры килде. Ул Сатыш мәдрәсәсе белән бәйле бик күп тарихый ядкярләрне, нәсел шәҗәрәләрен, үзенә килгән хатларны (алар арасында СССРның халык артисты, якташыбыз Шәүкәт Биктимеров белән Мөхәммәт Мәһдиевнеке дә бар) кадерләп саклый, алга таба музейга бирергә ниятли. Унынчы дистәне ваклаган Суфия апаның хәтере искиткеч әйбәт, тавышы горур, күңеле күтәренке. Алга узып шуны искәртергә кирәк, әле менә аңа күптән түгел - гыйнвар аенда гына 95 яшь тулды. Шул уңайдан район башлыгы Рәис Миңнеханов күпне күргән мөхтәрәмә ветеранга Россия Президенты Владимир Путинның котлавын тапшырды.

- Менә шушы Сатыш мәдрәсәсенең хуҗасы, мөдәррисе булып торган Габдерахман кызы инде мин, - диде Суфия апа, үзе өчен бик тә кадерле рәсемне кулына алып. - Язучы, әдәбият белгече Мөхәммәт Гали безгә килеп укыган, дип сөйлибез бит әле. Ул да якын туганыбыз: аның әтисе белән минем әти бертуган иде. Менә бу язмада әтинең апасының улы турындагы хатирәләр тасвирланган. Мамадыш районы Баскан авылы мулласының малае Габдулла исемле иде. Алабуга техникумында татар теле һәм әдәбияты укыткан елларда аның җәйге ялы Кырымда дәваланучы күренекле язучы Галимҗан Ибраһимов белән бергә туры килгән. Очрашканнар, сөйләшеп утырганнар. Соңыннан Габдулланы "милләтче" Ибраһимов белән элемтәдә торган, дип, 15 елга хөкем иттеләр. Менә, монысы - җизни, олы апаның ире, ул да сөрелде, - дип, тагын бер рәсемгә күрсәтеп алды Суфия Габдерахман кызы. - (Аннары, икенче сурәтне кулына алып, болай сөйләп китте:) Сугышта Гатауллин Гариф атлы, ул чор өчен күренекле бай бар иде. Энесе Зариф абый Кукмарада кибетләр тотты. Шуннан куылып, юкка чыгарылды. Гариф абый үзе безнең белән Магнитогорскка сөрелде һәм шунда мәңгелеккә калды. Ә әтиебез, Аллага шөкер, кайтып үлде. Җәсәде - авылыбыз зиратында. Безнең туганнар каберлегебез кирпеч белән әйләндереп алынган иде. Төрбә шикеллерәк итеп. Шуның кирпечен сүтеп, сугыш вакытында тегеләй-болай итеп бетергәннәр. Хәзер Казандагы энебез шул каберлекне яңадан әйләндереп алып, тәртипләп тота, Аллаһның рәхмәте булсын...

Хәзер инде, язмабызның соңында төп темага - Сатыш мәдрәсәсе тарихына тагын бер тукталыйк. Әлеге дә баягы "Татар халкының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре" дигән китапта: "Мәдрәсәнең бер катлы кирпеч бинасы XIX-XX гасыр чигендә төзелгән", - дип әйтелә. Әмма бу дөреслеккә бигүк туры килеп бетми кебек. Без, әйткәнемчә, Мәгъсум абый Хуҗин белән, "Яшә, Саба-Йорт" китабыбызда Сатыш мәдрәсәсенә, гомумән, бу авылның совет чорындагы мәгариф үсешенә хәйран зур урын бирдек. Шуның мәдрәсә өлешен кабат искә төшерим әле: "...Мәдрәсә XVIII гасыр азагында ачылган була. Ул хәзерге Кукмара районының Зур Сәрдек авылыннан Хаҗи Насыйбуллин акчасына төзелгән, дип исәпләнелә. Хаҗи үзе итек басу фабрикасы тоткан булса кирәк. Йон туплау максатыннан, Саба якларына да килеп чыга. Сатышта йон саклау склады төзетә. Биредә ялланып эшләүчеләр дә шактый булган, күрәсең. Аларга ул гыйбадәт кылу, балаларны укыту өчен мәдрәсә төзетергә була. Шушы изге йорт каршында яшәгән Габдерахман исемле кешенең әтисе 12 яшендә мәдрәсә төзелешенә кирпеч ташуда булышуы турында сөйли.

Мәдрәсә тарихына кагылышлы бер архив документының эчтәлеге белән танышу да укучылар өчен кызыклы булыр.

"1876 ел, 10 июнь. Казан губернасы, Мамадыш өязе, Сатыш авылы халкының мәдрәсәдә урыс телен укытуга каршылыгы турында "Эчке эшләр министры А.Лобанов-Ростовскийның идарәчегә мөрәҗәгате:

Идарә итүче М.Н.П.га!

Казан губернасы башлыгы М.В.Д.га!

Мамадыш өязенең Сатыш авылында 75 ел дәвамында татар мәктәбе эшли. Ул мәктәптә урыс теле өйрәтелмәгән. 1873 елның 29 сентябрендә өяз земствосында кабул ителгән карар буенча, Мамадыш өязе, шушы вакыйгага игътибар биреп, татар мәктәпләрендә урыс теле кертү өчен 300 сум акча җибәрде һәм аны өязнең өч әһәмиятле - Сатыш, Түбән Ушмы, Түбән Яке мәктәпләренә бүлде. Земство идарәсенең 1874 елда югарыда күрсәтелгән карарын гамәлгә ашыруга, ягъни мәдрәсәдә урыс грамотасын укытуга Сатыш авылындагы җирле халык тарафыннан каршылык күрсәтелде.

"Мәдрәсәләрдә урыс телен укытуны гамәлгә кертү турында" 1870 елның 25 март карарын үтәү буенча һәм крестьян-мөселманнарның моңа каршы килү очраклары өчен аерым карар булмаганлыктан, авыл халкына мәдрәсәдә урыс телен укыту халык хисабына түгел, ә бәлки земство бүлгән акчага икәнлеген аңлатырга.

1874 елның 20 ноябрь карары нигезендә, халык училищелары белән сак эш итәргә кирәклеге искәртелде. Казан губернаторының шушы вакыйга буенча күрсәтмәсенә нәтиҗә ясавыгызны сорыйм".

Әлеге язманың өлешчә күчермәсе менә шундый. Ул XVIII гасыр ахырында ачылган мәдрәсәнең XIX гасырның 70 нче елларында Казан губернасында игътибар үзәгендә торган мәктәпләрнең берсе булуын дәлилли, мәдрәсә тормышындагы әһәмиятле вакыйганы сурәтли. Аннан соң да мәдрәсә гыйлем бирү дәрәҗәсен югалтмаган.



**Раил ӘБУБӘКИРОВ** фотосында: ***Сатыш мәдрәсәсенең бүгенге халәте.***

**Тәлгать НӘҖМИЕВ,**
***Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре***

# АСЫЛТАШЛЫ ҖӘҮҺӘР

**Көмеш ае, мәһабәт бинасы белән шәһәребез үзәгенең матур бизәге булып тирә-юньгә нур чәчеп торган Мамадыш мәдрәсәсенә нәкъ дүрт ел элек укырга килдем.**

Мәдрәсә ачылган елны ук укырга кергән идем дә, бер ел укуны ташлап торырга туры килде. Аллаһы Тәгалә гел ярдәменнән ташламый, мәдрәсә дә яшәү урыным янында гына. Укымасам, гөнаһ булыр иде. Башка кешеләр ерак авыллардан да килеп укыйлар. Мәдрәсәгә килгәч уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары Ранил Талипов: "Укырга беркайчан да соң түгел, теләк кенә кирәк", - диде.

Әлифне таяк дип тә белмим. Гарәп алфавитын бер дә танырмын, аңлармын сыман түгел. Вакыт табып, Аллаһы Тәгаләнең ярдәме белән, бик теләп, яратып, бер генә уку көнемне дә югалтмыйча, шатланып мәдрәсәгә йөрим. Ранил хәзрәт безгә хәдисләр өйрәтә. Бу гыйлемле, бик итагатьле хәзрәт Түбән Каманың "Рисәлә" мәдрәсәсендә белем алган, хәзерге вакытта читтән торып Алабугада дөньяви белем үзләштерә. Ул табигате белән бик сабыр, тәвәккәл, тырыш, тыныч холыклы, хезмәттәшләренә һәм дусларына теләсә кайчан ярдәм кулы сузучан, изге, саф күңелле кеше. Аның беркайчан беркемгә карата усаллык, начарлык, тупаслык эшләгәнен яки берәр кешегә карата начар сүз әйткәнен күрмәссең дә, ишетмәссең дә. Менә биш ел инде мәдрәсәдә шәкертләр укыта.

"Рисәлә" мәдрәсәсендә укыганда бик яхшы билгеләренә генә укый. "Мәдрәсә ул - белем учагы. Ул учак бар кешеләрне җылыта, аларга бу дөньяда үз урыннарын табарга ярдәм итә", - ди Ранил хәзрәт. "Булдыра алмам гарәпчә укырга", - дигәч, ул миңа өстәмә дәресләр бирә башлады. Белем алу - бөтен кешегә фарыз гамәл. Пәйгамбәребез (с. г. в.) үзенең бер мөбарәк хәдисендә юкка гына: "Бишектән ләхеткәчә гыйлем алыгыз", - дип әйтеп калдырмаган. Ул безгә хәдисләр белән гел илһам өстәп торды.

"Гыйлем - динебезнең нигезе. Мөселман җанлы Адәм баласы гыйлем алуны үзенең тормышында төп бурыч итеп кабул итәргә тиеш. Ягъни, әгәр кулыңнан килсә, галим бул, моңа да ирешмәсәң, гыйлем мәҗлесләрендә гыйлем тыңла, монысын да эшли алмасаң, гыйлемне дус күр, аны ярат. Гыйлем - нур. Мөэминнең дөньялыкта сынау имтиханнарын уңышлы тапшыруы да, һичшиксез, гыйлемгә кайтып кала. Гыйлем алу сәбәпле, адәм баласы хәләлнең ни дә хәрәмнең ни икәнен таный", - дип, гыйлем алырга гел үсендереп торды. Аллаһның рәхмәте белән бу мөгаллимебез безгә дини гыйлем өйрәтте. "Фирая апа, һәрвакытта да Аллаһ Раббыздан хәерле вә файдалы гыйлем бирүен сорап дога кыл", - диде.



Сулдан икенче Ранил хәзрәт Талипов.

Дини мирасыбызны барлау, җентекләп фәнни-тикшеренү эшенә, аны халыкка аңлатуга күп көч куя. Моның өчен бик зур гыйлем, ихтыяр көченә ия булу, үҗәтлек дәрәҗәсендәге тырышлык, эш сөю, сабырлык һәм Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән сәләт, талант һәм сиземләү көче сорала. Ранил Талиповта боларның барысы да бар. Мәдрәсәдә укыган шәкертләр Ранил Талипов белән горурлана һәм аңа саулык-сәламәтлек тели.

**ИГЪТИБАР!**

***Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Мамадыш мәдрәсәсе 2013-2014 нче уку елына шәкертләр кабул итә.***

Белгечләр әзерләү көндезге, кичке һәм читтән торып уку рәвешендә алып барыла.

Көндезге бүлеккә яше ундүрттән дә түбән булмаган егетләр алына. Шәкертләр мәдрәсә тулай торагында яшәү урыны һәм көненә өч мәртәбә ашау-эчү белән тәэмин ителә. Уку вакыты - өч ел. Урта белем алу исә Мамадыш шәһәренең икенче лицеенда алып барыла.

Кичке һәм читтән торып уку бүлекләренә хатын-кызлар һәм ир-егетләр кабул ителә. Яшь буенча чикләүләр юк. Уку вакыты - дүрт ел.

Мәдрәсәне тәмамлаганнан соң, шәкертләргә квалификацион комиссия карары нигезендә тиешле белгечлекләрен алу турында диплом бирелә.

2012 елда мәдрәсә вакыты чикләнмәгән лицензия - уку-укыту эше алып бару өчен бирелгән рөхсәт язуы алды.

Мәдрәсәдә якшәмбе көнне кечкенә балаларга да белем алу мөмкинлеге тудырылган. Ай саен Мамадыш районы авылларында эшләүче имамнар өчен дә курслар үткәрелә. Җәйге канукулда балалар өчен лагерь оештырыла. Мәдрәсәнең "Нәсыйхәт" исемле үз газеты да чыгып килә.

Мәдрәсәнең адресы: **422190 Татарстан Республикасы, Мамадыш шәһәре, М.Җәлил урамы, 8/28 нче йорт.**

*Телефоннар: +7 (85563) 3-19-17, 89172802391 (Габдрахман хәзрәт Хәбибуллин).*

*Электрон почта адресы: mamadysh-medrese@mail.ru.*

**Фирая МИНГАЛИЕВА,**
**Мамадыш шәһәре**

# КУКМАРАНЫҢ “ИМАН КИЧӘСЕ”

***(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)***

Бу кичәдә моңлы тавышы һәм мәгънәле нашидләр, мөнәҗәтләр башкаруы белән инде танылып өлгергән Ильяс Халиков та катнашты. Ул Кукмарабыз кияве дә булып чыкты бит әле! Аның хәләл җефете Нурфия Кәркәвеч авылы кызы, Ильяс хәзрәт башкара торган барлык нашидләрнең сүзләрен иҗат итүче шагыйрә, сөбханалла! Нурфия белән без балачактан бирле таныш, әмма күп еллар күрешкәнебез юк иде. Шуңа күрә сөйләшер сүзләребез күп булды. Нурфия Ильяс хәзрәтнең хәләле генә түгел, аның иҗат эшчәнлегендә уң кулы да икән. Аларны никах-туйларга тамада булып та чакыралар, иман кичәләрендә һәм башка төрле дини чараларда еш катнаштыралар, болар өстенә алар ике бала да үстерәләр икән.

– Әле менә “Аклыкка илтсен юллар” дип аталган (театральләштерелгән) хәйрия концертына әзерләнеп ятабыз. 18 июньдә Казанның “Ак барс” яшьләр үзәгендә булачак ул. Университетта укыган бер группадашымның баласы авыру туган, концерттан акча туплап, аңа ярдәм итмәкче булабыз. Күптән түгел Ильяс башкаруындагы нашидләр җыентыгын диск итеп чыгардык. Буш вакыт булса, әти-әниләребез янына кайтабыз. Ирем Мамадыш ягыннан”, – дип сөйләде ул.

Район мәдәният йортында узган чарада катнашучылар өчен кичәдәге кызыклы өлешләрнең берсе викторина булгандыр. Бер карашка гади, әмма ислам дине белән азмы-күпме таныш булуны күздә тота торган сорауларга дөрес җавап бирүчеләр Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте вәкилләре алып килгән Коръән тәфсире белән бүләкләнде. Истә калган сорауларның берничәсе: “Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с. г. в.) сөт әнисе кем булган?”, “Хатыны Хәдичә белән аның яшь аермасы күпме?” “Фатыйха” сүрәсендә Аллаһы Тәгалә белән Адәм баласын “аерып торучы” аять нинди?” һ. б.

“Иман кичәсе”ннән соң аны оештыручыларның берсе, Кукмара мәдрәсәсе директоры Ришат Курамшин белән дә әңгәмә корып алдык.

– Мондый чараларны үткәрү, һичшиксез, бик кирәкле, файдалы гамәлләрдәндер, чөнки алар дәгъвәт, ягъни ислам динен танытуның, дингә, иманәхлакка өндәүнең бер мөһим ысулы булып тора. Вәгазь һәм җыр аша бирелә Аллаһ һәм Пәйгамбәребез (с. г. в.) исемнәре, башка изге сүзләр һәм бик мөһим фикерләр яңгырады. Без рухланып-канатланып, күңелләребезне баетып кайтып китәбез, шуның белән бергә Аллаһы Тәгаләнең әҗер-савапларына да лаеклы булганбыздыр дип өмет итәбез... – диде Ришат хәзрәт.

Менә шулай бәйрәм итә мөселман халкы! Изге сүз сөйләшеп, вәгазь, Коръән тыңлап та ял итеп була икән, җәмәгать!

**Гөлназ ГАЛИМҖАНОВА,**
**Кукмара районы**

# 2013 елга "ДУМ РТ ХАДЖ" тәкъдиме

**Программаның максаты - хаҗ сәфәрен кулай (оптималь) бәядән киң катлам халык өчен уңай хәл итү, яшәү һәм хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшырту. Хаҗ программасы РФ Хөкүмәтендәге Хаҗ Советы таләпләренә туры килә, ул җентекләп эшләнгән һәм ышанычлы булуы белән аерылып тора.**

Әлеге хаҗ тәкъдиме башкаларга да үрнәк - ул барлык үтәлергә тиешле хезмәтләрне дә үз эченә алган.

**ТӘКЪДИМГӘ ТҮБӘНДӘГЕЛӘР КЕРӘ:**

***1) Казаннан Җиддәгә (Согуд Гарәбстанының көнбатыш өлешендәге шәһәр), Мәдинәдән Казанга турыдан-туры рейслар; шулай ук Мәскәүдән, Уфадан, Оренбургтан, Түбән Камадан да турыдан-туры очып китү каралган;***

***2) Казаннан очу вакыты (якынча) - 2013 елның 1-8 октябре көннәрендә; Казанга кире әйләнеп кайту (якынча) - 2013 елның 19 октябреннән шул ук елның 10 ноябренә кадәр;***

***3) сәфәр озынлыгы - 19-25 көн;***

***4) Мәккәдәге кунакханә Әл-Хәрәм мәчетеннән 3,5 километр ераклыкта урнашкан; Әл-Хәрәм мәчете - дөньядагы иң зур һәм иң төп гыйбадәтханәләрнең берсе;***

***5) кунакханә 4-8 кешелек бүлмәләрдән гыйбарәт. Хаҗәтханә (туалет) белән юыну урыны кунакханә бүлмәләренең үзендә яки янында; барча уңайлыклар Согуд Гарәбстанының Хаҗ Вәзирлеге таләпләре кысаларында башкарыла;***

***6) көненә ике тапкыр ашату; чәй белән каһвәне (кофены) тәүлек дәвамында куллану мөмкинлеге;***

***7) Мәдинәдә яшәү вакыты - 3 көн. Мәдинә - Согуд Гарәбстанының көнбатыш өлешендә (Хиҗаз өлешендә) урнашкан шәһәр;***

***8) медицина иминияте һәм тәүлек әйләнәсендә табиб (врач) ярдәме күрсәтелү;***

***9) Согуд Гарәбстанының бер урыныннан икенче урынына (Мина-Гарәфәт-Мөздәлифә, Мәккә-Мәдинә) хәрәкәт итү өчен автобус белән тәэмин ителү;***

***10) Зәмзәмнән (Мәккәи-Мөкәррәмәдә Кәгъбә янындагы изге кое) биш литр су алып кайту;***

***11 хаҗ сәфәре вакытында кирәкле барлык әйберләр белән дә тәэмин ителү (китаплар, ике сумка, намазлык);***

***12) һәр төркемдә имам-җитәкче булу;***

***13) корбан чалу йоласын башкару;***

***14) ир-атларга ихрам киеме (хаҗилар өстендәге ике ак тукыма);***

***15) җирле SIM-карталар (мобиль элемтәдә абонентка куллану өчен туры килгән модуль);***

***16) хаҗиларны фоторәсемгә һәм видеоязмага төшерү.***

"ДУМ РТ Хадж" белән түбәндәге телефоннар аша элемтәгә керергә мөмкин: **+7 (843) 524-92-10, +7 (843) 240-53-98, +7 (843) 200-93-11.**

Адресыбыз: **420021 Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 3 нче йорт.**

Интернеттагы сайт: **www.dumrt-haj.ru.**

Электрон почта адресы: **5249210@gmail.com.**

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 24 (193) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** № 35407.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция һәм нәшер итүче адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27. "Дин вә мәгыйшәт" газетасы редакциясе. Язылу индексы - 16046.
***График буенча бу санга 14 июнь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга куллanudan сакланыгыз!**